**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 22 июль № 539

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлекләрен раслау турында» 2011 ел, 21 сентябрь, 784 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлекләрен раслау турында» 2011 ел, 21 сентябрь, 784 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 18 декабрь, 1101 нче; 2013 ел, 24 май, 349 нчы; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2015 ел, 19 март, 167 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлегенә (карарга теркәлә), аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\539.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2011 ел, 21 сентябрь, 784 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 22 июль, 539 нчы
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеге

| Вазыйфа | Вазыйфаи эшчәнлек |
|---|---|
| Министр урынбасары (дәүләт экология күзәтчелеге мәсьәләләре өчен җаваплы) | Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге баш дәүләт инспекторы |
| Экология күзәтчелеге дәүләт инспекциясе башлыгы;<br>территориаль идарәләр башлыклары | Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге баш дәүләт инспекторы урынбасарлары |
| Экология күзәтчелеге дәүләт инспекциясе башлыгы урынбасары;<br>территориаль идарәләр башлыклары урынбасарлары | Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге өлкән дәүләт инспекторлары |
| Территориаль идарәләрнең махсуслаштырылган инспекцияләре башлыклары, территориаль идарәләрнең махсуслаштырылган инспекцияләре башлыклары урынбасарлары;<br>Экология күзәтчелеге дәүләт инспекциясенең консультантлары, 2, 3 разрядлы өлкән белгечләре;<br>территориаль идарәләрнең махсуслаштырылган инспекцияләре баш белгечләре;<br>территориаль идарәләрнең махсуслаштырылган инспекцияләре әйдәп баручы белгечләре;<br>территориаль идарәләрнең махсуслаштырылган инспекцияләре 1 категорияле белгечләре;<br>территориаль идарәләрнең консультанты, 2, 3 разрядлы өлкән белгечләре;<br>территориаль идарәләрнең 1 разрядлы белгечләре | Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге дәүләт инспекторлары |